**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет
Тойкинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района**

ул. Джалиля , д. 19, село Тойкино,
Азнакаевского муниципального
района, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге
башкарма комитеты**

Җәлил урамы,19, Туйкә авылы
Азнакай муниципаль районы, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 декабрь 2017 ел. № 26

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар һәм биналар исемлеге һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урыннар бирү тәртибе турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына гавами чаралар турындагы законнарны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 7 июнендәге 107-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Туйкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар исемлеге (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Туйкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен биналар исемлеге (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибе (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-

коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова